**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.01.2015 № 56

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет һәм автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә беркетү турында

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет һәм автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге N273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, 67 статьясы нигезендә территориаль үтемлелеген тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре муниципаль берәмлеге территорияләрен Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре мәктәпкәчә белемнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының һәм Нурлат шәһәренең муниципаль бюджет һәм автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә беркетергә.

2. Муниципаль бюджет һәм автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарны Интернет челтәрендә балалар бакчалары сайтларында урнаштырырга кирәк.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф буенча җитәкчесенең урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин